Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

«14» ноябрь, 2024 ел № 11

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Югары Китәк поселогында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Югары Китәк поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Сәрдек авылы, Яңа ур., 2а адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Югары Китәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**(юлларга вак таш һәм асфальт салу, карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Югары Китәк поселогында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Китәк торак пунктында агачларны кисү, ял итү зоналарын булдыру, төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, хоккей мәйданчыгын ремонтлау һәм карап тоту;

проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү**;(Югары Китәк поселогы зираты территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре); (Югары Китәк поселогы зиратында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, зиратны төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Югары Китәк поселогының су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре; Югары Китәк поселогында коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, урам электр челтәрен төзү, карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (Югары Китәк поселогында янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, ДЕПОны ремонтлау, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Сәрдекбаш авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы И.М. Нәбиев